Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге Советының унберенче утырышы

Кибәч авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

10 сентябрь, 2021 ел № 25

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Кибәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 12 октябрендәге 14 номерлы Кибәч авыл җирлеге Советы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Кибәч авыл җирлеге уставы нигезендә **Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. Кибәч авыл җирлеге Советының 2015 елның 12 октябрендәге 14 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Кибәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» карары (2018 елның 13 декабрендәге 14 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип санарга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында www.pestreci.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Рәимов